РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
БЮРГАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БОЕРГАН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

2020 елның 21 мае 88-5 нче номерлы

2014 елның 26 декабреннән № 1-53 номерлы
Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге
Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы
Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең
халык дружинасы турында нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы, Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советы, Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Боерган авыл җирлегенең халык дружинасы турында»гы нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең 6.3 пунктының 9 абзацын түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм расларга: «Халык дружинасына кабул ителгән көн алдыннан берничә тапкыр дәвамында, алдан уйлап административ хокук бозулар өчен суд тәртибендә административ җәзага тартылган;».

2. Әлеге карар рәсми бастырылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча http://buinsk.tatarstan.ru урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Буа муниципаль районы
Боерган авыл
җирлеге Советы рәисе И.В. Малышева